КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 30 декабрь г.Казань № 1257

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү турында» 2018 ел, 19 гыйнвар, 19 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү турында» 2018 ел, 19 гыйнвар, 19 нчы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

4 пунктта «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре һәм спорт министрлыгы» сүзләрен «Татарстан Республикасы Яшьләр эшләре министрлыгы» сүзләренә алмаштырырга;

әлеген карар белән расланган Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнеше бердәм системасында балалар төркемнәре белән юл йөрүләрне оештыру буенча ведомствоара хезмәттәшлек итү тәртибендә:

1.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.2. Әлеге Тәртип Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Балаларны автобуслар белән оешкан төстә йөртү кагыйдәләрен раслау турында» 2020 елның 23

сентябрендәге 1527 номерлы (алга таба - 1527 номерлы карар), «Россия Федерациясендә туризм иминлеген тәэмин итүнең кайбер мәсьәләләре турында» 2017 елның 3 мартындагы 252 номерлы карарлары, Россия Федерациясе Баш дәүләт санитария табибының «Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләрен һәм СанПин 2.3/2.4.3590-20 нормаларын раслау турында» 2020 елның 27 октябрендәге 32 номерлы карары белән расланган Халыкның җәмәгать туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләре һәм СанПин *2.3*/*2.4*.3590-20 нормалары, Россия Федерациясе Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы баш дәүләт инспекторы һәм Россия Федерациясенең Баш дәүләт санитар табибы тарафыннан 2006 елның 21 сентябрендә расланган Балалар төркемнәрен автомобиль транспортында йөртүнең санитар-эпидемиологик иминлеген һәм куркынычсызлыгын тәэмин итү буенча методик рекомендацияләр нигезендә эшләнгән.»;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Инициаторга Татарстан Республикасының ведомствоара электрон документлар әйләнешенең бердәм системасында мәгълүмат хатына беркетергә һәм әлеге Тәртипкә кушымта нигезендә ведомство карамагындагы рәвеш буенча түбәндәгеләрне килештерүгә җибәрергә тәкъдим ителә:

күчмә чыгуның нигезе (муниципаль берәмлек башкарма комитеты күрсәтмәсе, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы боерыгы, укыту планы, мәктәптән тыш эшчәнлек планы яисә, теркәлү номерын һәм датасын күрсәтеп, балалар төркемнәрен чыгуны оештыру турында белем бирү оешмасының боерыгы);

«Автомобиль транспорты һәм шәһәр җир өсте электр транспорты уставы» 2007 елның 8 ноябрендәге 259-ФЗ номерлы Федераль закон (балалар төркемен оешкан төстә күчереп йөртү фрахтование килешүе буенча гамәлгә ашырылса) нигезендә төзелгән фрахтование килешүе;

Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә күзәтчелек федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсе тарафыннан билгеләнгән ассортименттан азык-төлек продуктлары (коры паекалар, шешәдә су) җыелмасы исемлеге (бару юлындагы дүрт сәгатьтән кимрәк вакыт булган балалар өчен);

балалар төркемнәрен оешкан рәвештә йөртүчеләр дүрт сәгатьтән артык автомобиль, су һәм транспортның башка төрләре юлында кайнар туклану оештыру турындагы белешмәләр (23:00 дән 7:00 сәгатькә кадәр төнге вакыттан тыш);

ташу процессында автобуста булырга рөхсәт ителә торган затлар исемлеге. машина йөртүчедән (машина йөртүчеләрдән) тыш, шул исәптән:

төркем составына кертелгән балалар, һәр баланың фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта), яшен яисә туу датасын, шулай ук аның ата-анасының (законлы вәкилләренең) контактлы телефоннары номерларын күрсәтеп,

озатып йөрүче затлар, аларның фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта) һәм контакт телефоны номерын күрсәтеп,

медицина хезмәткәре, аның фамилиясен, исемен, атасының исемен (булган очракта) һәм контакт телефоны номерын күрсәтеп - 1527 номерлы карарның 11 пунктында каралган очракта;

ирекле рәвештә төзелгән, ташу маршруты турында белешмәләр булган документ, шул исәптән түбәндәгеләр турында:

кузгалып китү пункты,

балалар төркемен оешкан төстә алып баруда катнашучы балалар һәм башка затларны утыртуның (төшерүнең) арадаш пунктлары (әгәр булса),

билгеләү пункты,

ризык кабул итү, кыска вакытлы ял итү, төнге ял итү урыннары (күп көнлек сәяхәтләр вакытында) – балалар төркемен шәһәрара оешкан төстә күчереп йөрткән очракта;

Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының «Балаларны автобусларда йөртүне оештыру турында хәбәрнамә бирү тәртибен раслау турында» 2016 елның 30 декабрендәге 941 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе идарәсенә хәбәрнамә бирү тәртибе нигезендә балалар төркемен автобусларда йөртүне оештыру турында хәбәрнамә, хәбәрнамә бланкындагы керүче номеры һәм теркәү датасы белән; яисә Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Юл хәрәкәте куркынычсызлыгы дәүләт инспекциясе идарәсе бүлекчәләренең автобусларны автомобиль (автомобильләр) белән озатуга гаризасын карау нәтиҗәләре буенча тискәре карар кабул итү турында хәбәрнамә күчермәсе (мондый карар кабул ителгәндә);

Россия Федерациясе Баш дәүләт санитар табибының «Оештырылган балалар төркемнәрен тимер юл транспортында йөртүгә карата санитар-эпидемиологик таләпләр» 2.5.3157-14 СП раслау турында» 2014 елның 21 гыйнварындагы 3 номерлы карары белән расланган Оештырылган балалар төркемнәрен тимер юл транспортында йөртүгә карата санитар-эпидемиологик таләпләр 2.5.3157-14 СП 1 нче кушымта нигезендә форма буенча Кулланучылар хокукларын яклау өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе органнарына хәбәрнамә (Татарстан Республикасыннан читкә чыгуны оештырганда);

«Пассажир ташучының тормышына, сәламәтлегенә, мөлкәтенә зыян китергән өчен гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү һәм метрополитенда пассажирлар йөрткәндә китерелгән зыянны каплау тәртибе турында» 2012 елның 14 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә пассажирларның тормышына, сәламәтлегенә, мөлкәтенә зыян китергән өчен пассажир ташучының гражданлык җаваплылыгын мәҗбүри иминләштерү шартнамәсе;

туристлык продуктын сату турында заказчы (инициатор) һәм туроператор арасындагы шартнамә (заказчыга (инициаторга) шартнамә төзегәндә Туризм буенча федераль агентлыкның рәсми сайтында https://tourism.gov.ru/operators/ адресы буенча туроператор турында мәгълүматлар булуны тикшерергә тәкъдим ителә) («туроператорларның бердәм федераль реестры» бүлеге) – заказчы (инициаторы) һәм туроператор арасындагы килешү буенча балалар төркемнәренең чыгуы оештырылган очракта.».

2. Әлеге карар, 2021 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә торган һәм 2027 елның 1 гыйнварына кадәр гамәлдә булган 1 пунктның дүртенче – егерме бишенче абзацларыннан тыш, басылып чыккан көненнән үз көченә керә дип билгеләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин